СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№237 от 04.05.2018
на № _________от ______________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының балигъ булмаган балалар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасының 2011 елның 20 маендагы 26-ЗРТ номерлы “Татарстан Республикасында балигъ булмаган балалар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссияләр хакында” гы Законының 7 матдәсенә нигезләнеп һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының балигъ булмаган балалар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең кайбер әгъзаларының вазыйфаларыннан китүләре сәбәпле, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының балигъ булмаган балалар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2012 елның 26 апрелендәге 116нчы номерлы карары белән (2013 елның 23 сентябрендәге 211 номерлы, 2015 елның 30 апрелендәге 304 номерлы, 2015 елның 23 октябрендәге 20 номерлы, 2016 елның 28 апрелендәге 58 номерлы, 2016 елның 16 декаберендәге 86 номерлы, 2017 елның 29 августындагы 164 номерлы, 2017 елның 07 ноябрендәге 179 номерлы, 2018 елның 09 гыйнварындагы 193 номерлы, 2018 елның 21 февралендәге 203 номерлы редакцияләрендә) расланган “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының балигъ булмаган балалар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе турында”гы комиссия составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Комиссия составыннан Д.Г.Минһаҗеваны чыгарырга;

1.2. Комиссия составына:

- Саба муниципаль районы Башкарма комитетының тәртип саклау җәмәгать пунктлары эшчәнлеген тәэмин итүче әйдәп баручы белгеч, комиссия әгъзасы итеп А.Р. Исхакованы (килешү буенча);

- “Саба район үзәк хастаханәсе” дәүләт сәламәтлек саклау учреждениесенең табиб-наркологы И.Г. Муртазиннны кертергә (килешү буенча).

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы башлыгы урынбасары Р.Р.Закирҗановка йөкләргә.

Саба муниципаль районы Башлыгы Р.Н. Минниханов